**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

25 июнь 2025 ел №30 Урыссу ш.т.б.

"Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге Иҗтимагый советы
составының өчтән берен раслау турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 21.07.2014 ел, № 212-ФЗ Федераль закон, «РФ субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 23.06.2016 № 183-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында" 27.04.2017 ел, № 24-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 20.07.2017 ел, № 62-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Иҗтимагый советы турында Нигезләмәне раслау хакында" 14.10.2024 ел, № 27 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Иҗтимагый советы турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Иҗтимагый советы составының өчтән берен расларга:

1) Дәүләтбаева Юлия Рамазан кызы - Ютазы таңы («Ютазинская новь») вакытлы матбугат басмасының баш мөхәррире;

2) Брыль Татьяна Михайловна - "Горьковское" ТИҮ рәисе;

3) Якимова Нина Викторовна - Ютазы муниципаль районының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле ярдәмчесе;

4) Глушкова Зоя Васильевна - Пенсионер;

5) Шмуровец Валентина Федоровна - Пенсионер.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/ һәм Ютазы таңы («Ютазинская новь») вакытлы матбугат басмасында (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык № ФС 07.12.2011 Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
2-42-05